РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**Исполнительный комитет
Чубар-Абдулловского
сельского поселения
Азнакаевского
муниципального района**

ул. Советская, д.81, с.Чубар-Абдуллово,
423323
Тел. (8-88592), 38-7-37

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**Азнакай муниципаль районы
Чубар-Абдул авыл җирлеге
башкарма комитеты**

Совет урамы, 81, Чубар-Абдул авыл
423323
Тел. (8-88592), 38-7-37

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
15.03.2021

**КАРАР**
№5

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Чубар-Абдул авыл җирлеге» территориясендә урнашкан су объектларында су коенуны тыю турында

Россия Федерациясе Су кодексының 6 статьясындагы 4 өлеше, Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясенең 2020 елның 12 маендагы № 13-20р күрсәтмәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы « Чубар-Абдул авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә халыкның күпләп ял итүе һәм суда коткару чаралары өчен җиһазландырылган урыннар булмау сәбәпле, су объектларының һәм елгаларының санитария-гигиена нормаларына туры килмәве, елгаларда һәм сулыкларда бәхетсезлек очракларының иминлеген тәэмин итү, кисәтү һәм санын киметү максатыннан Чубар-Абдул авыл җирлеге Башкарма комитеты карар итә:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Чубар-Абдул авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан су объектларында су коенуны тыярга.

2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы территориясендә урнашкан « Чубар-Абдул авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең барлык милек рәвешләрендәге предприятие, оешма, учреждениеләр җитәкчеләренә су объектларында су коенуны тыю турындагы әлеге карар белән танышуны тәэмин итәргә тәкъдим итәргә.

3. Чубар-Абдул _авыл җирлеге Башкарма комитетына су объектлары янында су коенуны тыю турындагы мәгълүмат белән кисәтү аншлаглары урнаштырырга.

4. Әлеге карарны "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында" түбәндәге веб -адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының мәгълүмат сайтында "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatarstan.ru.

Башлык Н. Ә. Фәтхетдинов